| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НИЖНЕТАБЫНСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br><br>**СОВЕТ НИЖНЕТАБЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br><br>**ТҮБӘН ТАБЫН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |
|---|---|---|

*Юрид.адрес: 423977, РТ, Нижнетабынский район, с. Нижний Табын, ул. Молодёжная, 10*
*Факт.адрес: 423977, РТ, Нижнетабынский район, с. Верхний Табын, ул. Тукая, 19б*
Тел./факс: 8-85556-32874/Элект. адрес: Ntab.Mus@tatar.ru
ИНН 1629001040, КПП 162901001, ОГРН 1021605558435, ОКТМО 92642450

**Югары Табын авылы** **25 нче октябрь, 2019 нчы ел**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ТАБЫН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ III ЧАКЫРЫЛЫШ XL УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 2**

**Түбән Табын авыл җирлеге Советының 10 нчы декабрь 2018 нче елның № 3 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Мөслим районы прокуратурасының 29.01.2019 ел, № 02-08-02-2019 күрсәтмәсен карау нәтиҗәләре буенча, Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Түбән Табын авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Советының 10 нчы декабрь 2018 нче елның № 3 номерлы «Җир салымы турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) түбәндәге эчтәлекле өлеш өстәргә:

«3. Салым ташламаларын бирергә:

3.1. шәхси торак йортлар, шәхси ярдәмче хуҗалык, дачалар, бакча йортлары, гаражлар һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә (өлешләргә) карата җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләренә – физик затларга;

3.1.1. Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм Бөек Ватан сугышы инвалидларына;

3.1.2. Әфганстан республикасында интернациональ бурычларын үтәгән гражданнарга;

Әлеге карарның 3.1.1 – 3.1.2. пунктчаларында санап үтелгән салым түләүчеләр категориясенә керүче физик затларга ташлама 5000 кв. метр мәйданнан артмаган күләмдә салым салынмый торган җир кишәрлеге (өлеше) рәвешендә бирелә.

Әлеге карарның 3.1.1 – 3.1.2 пунктчаларында санап үтелгән салым түләүчеләр категориясенә керүче физик затларга һәм Түбән Табын авыл җирлеге территориясендә берничә җир кишәрлеге (өлешләре) булган кешеләргә салым ташламасы салым түләүченең теләге буенча бары тик бер җир участогы (өлеш) өчен генә бирелә.

Торак фонды биләгән җир кишәрлегенә (өлешенә) карата салым ташламасы анда салым түләүченең законнарда билгеләнгән тәртиптә даими теркәлүе (пропискасы) булган торак фонды объекты урнашкан җир кишәрлеге (өлеш) өчен бирелә.

3.2. салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләренә 100% күләмендә җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә:

3.2.1. оешмаларга – җирләү өчен бирелгән кишәрлекләргә карата.

3.2.2. сәнәгать билгеләнешендәге җир кишәрлекләрендә инвестицион бизнес-проектларны тормышка ашыручы инвесторларга».

б) 3,4,5,6,7 өлешләрен 4,5, 6, 7, 8 өлешләре дип санарга.

2.Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң бер ай үткәч үз көченә керә һәм 2020 нче елның 1 нче гыйнварыннан җир салымын исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

***Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл Советы рәисе, җирлек башлыгы*** ***Р.Ш. Кыяметдинов***